КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 гыйнвар г.Казань № 48

Россия Федерациясе гражданнары, шул исәптән авыл җирендә яшәүче 65 яшь һәм аннан өлкәнрәк булган затларга, медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә хосусый медицина оешмаларын җәлеп итү буенча сынау проектын Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле органны билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларында Россия Федерациясе гражданнары, шул исәптән авыл җирендә яшәүче 65 яшь һәм аннан өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә шәхси медицина оешмаларын җәлеп итү буенча сынау проектын гамәлгә ашыру турында» 2019 ел, 27 декабрь, 1915 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2020 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру кысаларында Россия Федерациясе гражданнары булган 65 яшь һәм аннан өлкәнрәк, шул исәптән авыл җирендә яшәүче затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә хосусый медицина оешмаларын җәлеп итү буенча сынау проектын гамәлгә ашыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасында әлеге пилот проектын гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин